Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлеге составына керүче Красный Ключ торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елның 30 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Красный Ключ авыл җирлегенең Красный Ключ торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Красный Ключ авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, белем алуның көндезге формасында белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның тормыш иптәшеннән тыш; 2 нче төркем инвалидларына һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерларга, күпбалалы гаиләләргә 50% түләү белән, 500 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

- зиратны төзекләндерүгә (зират территориясен койма белән әйләндереп алу, зират территориясендә агачларны санитар кисеп алу, төпләү) юнәлтергә (подряд шартнамәләрен барлык эш төрләре буенча түләү).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красный Ключ авыл җирлеге башлыгы И.К. Зәйнетдинов